Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2:256)

بسم الله الرحمن الرحيم

# Ислам нуры

№ 9 (637) 4 май, 2017 ел (1438, Шәгъбан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Габделәзәл хәзрәт: “Аллаһыдан сорасаң сораганыңны бирә, без моны үзебез генә сизмибез”

***Татарстан мөселманнарының 17 апрельдә булып узган VII Корылтаенда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин өлкән яшьтәге дүрт имамга нәзарәтнең иң олы бүләге — “Халыкка хезмәт өчен” медален тапшырды. Алар арасында Чаллы шәһәреннән быелның 15 апрелендә 85 яшен тутырган Габделәзал Кәшфелгаян улы Низаметдинов та бар иде. Ул шәһәрнең “Билал” мәчетендә бүгенге көндә дә уңышлы имамлык итә.***

***Габделәзәл Кәшфелгаян улы гомеренең 44 елын машина йөртүче хезмәтенә багышлаган, ул гомере буена бер генә предприятиедә эшли. Октябрь революциясе ордены, күп медальләр кавалеры, РФ нең атказанган транспорт хезмәткәре, 6 бала атасы.***

***Без укучыларыбызны Габделәзәл хәзрәтнең тормышы белән якынырак таныштырырга булдык һәм аңа шул үтенеч белән мөрәҗәгать иттек. Ул моңа җавап итеп менә нәрсәләр сөйләде:***





— Минзәлә районының Шикәрле Каен авылында туып-үскән. Без үскәндә ул Бәзәкә дип атала иде .

— Менделеевский районының Бәзәкә авылыннан күчкән. 1932 елның апрелендә туганмын. Без 2-3 класста укыганда бригадир тырмага дәрестән кереп ала иде, ирләр калмады авылда, хатын-кызлар гына. Авыр сугыш чоры. Ул вакытта атлар да бик ябык, начар иде. Бригадир карап торганда ат бара, ул киттеме — тыңламый инде менә. Ат та белә бала-чага икәнне. Бер уч азык табып булмый иде җир өстеннән шуңа каптырырга — ий, хикмәт инде.

Әтине 53 яшендә хезмәт армиясенә алдылар — Горький заводына. Алар ел ярымда кешелектән чыкканнар иде. Отпускага дип кайтарып җибәргәннәр. Әти сөйләде: “Иптәшләрне авыл саен кереп күмеп кайттык, өемә кайттым дип күбрәк ашый да, үлә,”-ди. Безнең әти бик сабыр, аның ишедән тыела иде. Ул да кайтып җитте. Мин ул вакытта шул 3 нче класста идемме, мәктәптән кайтканда күрәм: Хуҗәмәт белән безнең арадагы сыртта (ике авыл арасы 12 чакрым) бер кеше басып тора. Кайтып сумканы ташладым да — балачак бит инде — малайлар белән чана шуабыз. Кичкә таба күзем төште — теге кеше һаман шунда сыртта тора. Мин мәктәптән кайтканда да шулай торадыр иде, хәзер дә тора. Әнигә кереп әйттем. Әни әйтә: “Әй, улым, атаң түгелме икән? Әйдә, барыйк әле.” Бәләкәй чананы алдык та, киттек. Барсак, әтәй. Бер урында басып тормаган инде ул, әкрен генә килгән. Аякларының хәле булмаган. Аны Сәмәкәйгә хәтле китергәннәр. Сәмәкәйдән соң китерүче булмаган. Әҗмәкәйдә туганнар бар иде. Сарайлыдан Әҗмәкәйгә китергәннәр. Шулай итеп әтине чанага утыртык та, алып кайттык. Хикмәт булды аны авылга алып кайту. Кем уйлаган аны, ничек итеп аңа күзем төшкән. Шуларны уйлап йөрим мин. Аллаһы Тәгалә белгертә инде. Әти отпускасы беткәч кире китә алмады. 1943 елны 44 кә каршы безнең басу кар астында калды. Яз көне башак чыккач кар өстеннән йөреп шул башакны җыеп кайтабыз да, кул тегермәнендә тарттырабыз. Башаклар кышын агуланган. Кемнең сыеры, кәҗәсе юк — алар үлде. Шул елны авылда 65 кеше җирләнде. Сөт агуны йомшарткан.

Шул елның май ае азагында әти вафат булды. Беркөнне әти әйтә: “Әйдә, улым, балыкка барыйк әле.” Авыл башына кадәр бардык та, җәтмә салдык. Әти бик ярата иде балык тотарга. Берничә кеше ат арбасы белән алып кайталар иде. Ул коры җирдә басып тора, мин суга кереп әйләнеп чыгам. Бер чиләк җыелды. Шул вакыт Минкамал дигән әби: “Кәшфелгаян, нишләп йөрисең анда суга кереп, Керәшенледә (Станково, аны Керәшенле дип тә йөртәләр иде) чуман-чуман кан түгәләр,” - ди. Йөгереп мендем - әби юк. Чокырларны да карыйм. Күзебезгә генә күренгән. Хәзер әтәй янына төштем — әтәй калтырый, бөтен җире селкенә. Кайтып киттек. Әнәй балыкны пешерергә куйды. Әтәй ятты. Иртә белән үлде. Менә шул вакытта чирме-шайтанмы — күренеп йөрделәр. Авылда бик гыйлемле кеше бар иде. Ул әйтә: “Чыгып киттеләр атка утырып, арба тулып, сөйләшә-сөйләшә,”- ди. Шуннан соң авылда чир бетте, кеше үлү дә тукталды.

Гаиләдә 12 бала булганбыз. Бишесе кечкенә чакларында ук үлгән. Җидебез үстек. Мин тугызынчысы идем. Әтәй әйтте: “Берүк моннан китегез!” 1945 елны чыгып киттек. Чөнки азакклы сарыкны сөйрәп алып чыктылар. Хәзер уйлап йөрим: нишләп шул кадәр кыландылар икән? Ике бик начар кеше бар иде. Югыйсә, үзләре сугышта да булып кайткан. Берсе аяксыз, берсе кулсыз. Барыбер үзләре дә үлеп бетте.

Әҗмәкәйгә күчеп килдек - әнәй белән бертуган түтәй шунда иде. Аларга килеп кыш чыктык. Яз көне Ивановадан түтәйләр кайтты. Булган акчалары белән Красный Чаллыдан бер өй алып, 1945 нең көзенә шунда күчтек. Анда 10 ел тордык. Армиягә киткәнче Элеватор тавындагы авторотада 3 ел эшләдем. Ул ярым хәрби санала иде. Андый-мондый хәл булса шундук чыгып китәсең. Рота командиры Тихон Степанович бик әйбәт кеше иде. Эшкә слесарь өйрәнчеге булып кердем. Ул вакытта машиналар кар астында калалар. Ротаның 150 машинасы бар иде, Америка фордлары. Буксировать итеп кабызалар. Мин боларга кулдан әйләндереп кабыза торган җайланма ясадым. Берсе шуны командирга сөйләгән. Бер картер ачып маташа идем — яныма Тихон Степанович килде, ул җайланманы ничек ясавым белән кызыксынды, “кем өйрәтте?” ди. Мин Кустовский фамилияле бер керәшен кешесенең өйрәтүен әйттем. Тихон Степанович бу эшне бик хуплады. Шуннан соң машина йөртергә таныклыгым булмаса да, үзен йөртергә кушты. Правасыз бер ел йөрттем.

1957 елның 26 октябрендә армиягә алдылар. Өч ел хезмәт иттем. Кабат авторотага кайттым. Тихон Степанович бик җылы каршы алды, үзеңнең машинага утыр, ди. “Әй салырга теләгем бар,”- дип йөк машинасы сорадым. Бер атнадан бирделәр. Аны сүтеп майладым, рессорларына хәтле. Мөслимгә йөрдем. Көн саен бер рейс ясыйм — 80 чакрым. Ул заман өчен бу күп иде. Чөнки юллар юк. Мин үзебезнең авыл ягыннан басу өстеннән йөрим. Боз ката торган иде — күперләр юк. Бозны вата-вата чыга идем. Әлмәт шәһәре җиткерелә башлагач шунда эшләдек, юлларга таш чыгардык. Сабан туе алдыннан кайтып урак өстенә җыендык. Аллага шөкер, бик әйбәт эшләдем — машина ватылып тормады, суга батып ятмадым, утта янмадым, дигәндәй. Әнкәйнең хәер-догалары булгандыр. Үзем дә әнкәйнең өйрәткәне буенча бисмилләсез ишектән чыкмадым. Алланың рәхмәте белән, кайвакыт сул аяк алга чыга бит. Шул вакыт минем эч поша инде: ни булыр икән? Көне буе уйлап йөрим: бер чакны тәгәрмәч тишелде. Шулай үтеп китәдер иде. Әнә шундый чаклар булды. Аллаһы Тәгаләдән сорасаң, сораганыңны бирә - үзебез генә белмибез, сизмибез. Әлхәмделиллаһи шөкер, 43 ел хөкүмәтнекендә эшләдем, 22 ел үземнең машина белән йөрдем. Эштән киткәндә шундый вакытка туры

*Дәвамы 2 нче биттә.*

килдем — директор чыгармый, юк, ди. Ә 100 кешене кыскартырга кирәк. 1992 елларны шундый вакыт булды: үгез кебек малайлар эш көтеп тора, эшләр бетте. "Бабай, кайчан чыгасың инде пенсиягә?"- дип утыралар. "Әнә бит, җитмәй бит әле," - дигән булам. Ә үзем оялам. Эштән әйләнеп кайтам да: "Әй, нишләп йөрим соң инде. Яшьләр эшсез утырсын,"- дим. Шулай киттем. Пенсиягә киткәндә машина бүләк иттеләр — "Иж-Комби". Шул машинаны сатып өй җиткердем. Мин тезелеш белән шөгыльләнәм — ә кешеләр минем яннан мәчеткә узып китәләр. Әйтәләр:

— Әй, ташла инде бу эшеңне, мәчеткә йөрергә кирәк.

— Йөрербез, Алла бирсә, йөрербез,- дим.

Эчемнән уйлыйм: "Мәчеттән кайтмас идем, шушы эшләремне башкарып чыга алсам." Үземне-үзем ачуланам: "Пенсиягә чыгып җүнле кеше өй җиткерәмени?" Шулай итеп 1995 елның сентябрь-октябрь айларына бетердем. 1996 елны яз чыгу белән Элеватор тавына газ кертергә җыена башладылар. Газ кертүче инженер: Әйдә, бабай, синнән башлыйк әле,"- ди. "Юк, мин әйтәм, миннән башлыйсы түгел. Счетчиксыз кертмисез. Ә счетчик кыйбат. Юк, мин быел булдыра алмыйм." Тәки көннәрдә. Күршеләрдән акча җыеп счетчик алып кайттым да, урамда беренче булып безгә газ керттеләр. Менә аннан соң китте — кешеләр яртыларын түгел, ящигы белән күтәреп йөриләр болар артыннан. Вакытлары юк. Алланың рәхмәте, нигә ялынган ул кеше миңа, гел рәхмәтемне укып бетерә алмыйм.

Бу вакытта инде мин мәчеткә йөридер идем.

Йорт салуга килгәндә, мин беренче йортны 1955 елның май аенда ук күтәреп куйган идем. Авторотада эшләүчеләргә җир бирделәр. Ул вакытта тауда чирәмлек, басу — бер багана да юк иде. Машиналар басу өстенә генә тезеп куелган килеш. Май җылыту, аккумуляторларны карау землянкаларда иде. Ул вакытта оешмаларга да бик авыр булды — бернәрсә юк, материаллар җитешми. Тихон Степанович бөтен эшчеләренә участокларны алды — 6 шар сотый җир бирделәр. Билгеле, ул әзрәк иде. Элеватор янында патша заманыннан калган бер урам бар иде — аларда 10-15 сотый. Түбәле бураны Афанасьеводан алып кайттым, тәрәзәләре дә уелмаган. Бура хуҗасы — ап-ак сакаллы бабай әйтә: "Без моны 1917 елны ук күтәреп куйган идек, сатам,"- ди. Малайлары 5-6 мы, унмы булган - барысы да Пермьдә, ди. Бура бик яхшы сакланган иде - бүрәнәләре күтәрешле түгел. Аскы баганасы бочка юанлыгындагы имәннән — кузгатып та булмый. Машина белән тарттырам — кузгала инде. Әмма күтәреп сала алмадык. Яңа йортны күтәргеч ул йортны Әлмәткә алып киттеләр.

Шулай итеп 1996 елга чыккач мәчеткә йөри башладым. Имам булып "Йолдыз" мәдрәсәсен тәмамлаган Данил хәзрәт килде, Рәвкать хәзрәт мәхәллә рәисе булды. Бик әйбәт кенә башланганнар иде, булган акчалар бетте, хәзрәтләр дә сүрелделәр. Алыш-биреш чоры башланды. 1999 елны госпитальдә ятканда имам итеп мине сайлаганнар. Беркем бернәрсә әйтми, үзебезнекеләр дә. Кайчагында әйтеп куялар, син мулла бит инде, дип. Ә мин берни аңламыйм. Аннан соң тагын берничә кеше имам булып эшләп китте. Булган акчаны бетерәләр дә, китеп баралар. Шулай сейфны ачып андагы кәгазьләрне карап утырам: "Бәрәч, мине бит сайлаган булганнар,"- дим. Шулай итеп эшкә тотындым. Акча кирәк. Мин имамлыкны өстемә алганда кассада 40 сум акча бар иде. Шуннан өч кеше мәет юарга тотындык. Чаллының бер башыннан икенчесенә. Акча кирәк. Йөрим-йөрим, шуннан уйлыйм: "Мулла булып йөрисең, ә кулында кәҗә билеты да юк бит. Укырга кирәк." Шулай 10 елым узды. "Ак мәчет" мәдрәсәсенә укырга йөри башладым. Йөри-йөри йөрәк чире эләкте. Килә дә тертә. Дәрестән чыгып буш бүлмәләрдә ятып торам. "Үлсәм үләм, дин юлында үләм,"- дип үз-үзем белән сөйләшәм. Тәки, Аллаһның рәхмәте, бүгеге көнгә кадәр эшләп йөрим. Мәчетебезнең бурычлары юк, 19-20 кеше намазга йөри. Элеваторда эшләүчеләр дә хәтта өйлә намазын калдырмыйлар.

Хәләл җефетем Рәхилә Ибраһим кызы белән биш кыз, бер ул тәрбияләп үстердек. Ул да кирәген укый, кирәгенә өшкерә. Балаларыбызның барсына да югары белем бирдек. Үзләре тырышалар, тәртипле булдылар. Дүрт балабыз укырга киткәч, уйлап йөрим: болар бит кайтмаячак. Картайган көнебездә нишләрбез? Тагын ике бала алып кайтырга туры килде. Бер балабыз 79 да, икенчесе Олимпиада булганчы туды. Безне Олимпиадага барырга исемлеккә керткәннәр иде. Львовка машина алырга бардым. Анда 20 көнләп булдым. Машиналарны алып тезеп куйгач Мәскәүдән килделәр. Шуннан соң мин алдым да 15 машинаны Чаллыга җибәрдем. Казаннан 150 машина белән трест башлыгы килде: "Львовтан кайткан машиналар кая?" - ди. "Теләсәгез нишләтегез, мин аларны Чаллыга җибәрдем," - дим. Ярар инде," - дип көнделәр. Шулай итеп ул вакытта 15 машина алып калдык.

**Рәсемнәрдә:** мөфти Камил хәзрәт VII корылтайда Габделәзәл хәзрәтне бүләкләгәннән соң; Габделәзәл хәзрәт Чаллының "Ак мәчет"ендә ветераннар очрашуында чыгыш ясый.

# Ураза тотучыга сөннәт һәм мөстәхәб булган нәрсәләр

1. Йокыдан сәхәргә тору сөннәт. Моның Коръәни-Кәримдә дәлиле бар:

«...Сәхәр дә ашагыз, эчегез, хәтта таң якынлыгы беленгәнче, аннары уразаны тотып, тәмам итегез кояш баеганчы!» («Бәкара» сүрәсе, 187 нче аять).

Ибн Әбү Ләйла (рәхмәтуллаһи галәйһи) болай дигән: «Исламның беренче елларында берәр кеше уразасын бозганнан соң берни дә ашамыйча йокласа, икенче таңга кадәр берни дә ашамаган (сәхәргә тору булмаган). Шулай ук ир үз хатыны белән җенси якынлыкка да кермәгән». Мөгаз Ибн Җәбәл (радыйаллаһу ганһү) болай дигән: Гомәр Ибн Хаттаб (радыйаллаһу ганһү) бер рамазан төнендә хатыны янына килеп, аның белән якынлык кылырга теләгән. Хатыны: «Мин ифтардан соң йокладым», - дигән. Хәзрәти Гомәр (радыйаллаһу ганһү), хатынының ялганлап акланмакчы булуын белгәч, аның белән якынлык кылган.

Шулай ук ул төнне әнсарлардан бер кеше ахшам өенә килеп ашарга теләгән. «Сиңа бераз ризык җылытып бирик», — дигәннәр. Ләкин ул шунда ук йоклап киткән, ризыгын да ашамаган. Иртән аның хакында: «Рамазан аенда авыз ачканнан соң таңга хәтле хатыннарыгызга якынлык кылу хәләл ителде» («Бәкара» сүрәсе, 187 нче аять) дигән аять иңдерелгән һәм имсакка кадәр ашау-эчү, ир белән хатынының якынлык кылулары хәләл ителгән.

Һиҗрәттән соң уразаның фарыз кылынган беренче көннәрендә рамазан төннәрендә ифтардан соң йокласалар, иртәгесе көннең ахшамына кадәр берни дә ашамаганнар, сәхәргә дә тормаганнар. Шулай ук, рамазан төннәрендә хатыннары белән якынлык та кылмаганнар. Гомәрнең (радыйаллаһу ганһү) хатыны белән якынлык кылуы, әнсарлардан Сырманың (рәхмәтуллаһи галәйһи) ашамыйча йоклап китүе, шушы аятьнең иңдерелеп, рамазан төннәрендә җенси якынлык кылуның һәм сәхәрдә ашау-эчүнең хәләл булуы белдерелүенә сәбәп булды (Әбү Дауд, «Саләт», 28; Әхмәд Ибн Хәнбәл, 5/246).

## СӘХӘРНЕҢ ФАЗЫЙЛӘТЕ ХАКЫНДАГЫ РИВАЯТЬЛӘР, ХӘДИСЛӘР

Әнәс Ибн Мәлик (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм): «Сәхәр ризыгы ашагыз, чөнки сәхәрдә бәрәкәт бар», — дип әмер иткән (Бохари, «Саум», 20; Мөслим, «Сыйам», 45; Тирмизи, «Саум», 17).

Амр Ибнил Ас (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән: «Безнең уразабыз белән әһле китапның уразасы арасында аерма шунда: без сәхәр ашыйбыз» (Мөслим, «Сыйам», 46; Тирмизи, «Саум», 17; Нәсаи, «Сыйам», 27; Дарими, «Саум», 9; Әхмәд Ибн Хәнбәл, 4/194).

Әбү Сәгид әл-Худри (радыйаллаһу ганһү) тапшырган хәдистә Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай әйткән: «Сәхәр ашау бәрәкәтле, аны ашамыйча калмагыз. Һич булмаса, арагыздан берегез бер йотым су эчсен, чөнки Аллаһы Тәгалә һәм фәрештәләре сәхәр ашаганнарга саләт әйтә (муллык һәм нур яудырырлар)» (Әхмәд Ибн Хәнбәл, «Әл-Мүснәд», 3/12, 44, 4/377).

Сәхәр ашарга йокыдан тору көндез тотылачак ураза өчен көч туплау була. Моңа ишарәләп Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән:

«Көндезен йоклап алыгыз, төнлә торып тәһәҗҗүд намазын укыгыз, сәхәр ашап, көндезге уразагыз өчен көч туплагыз» (Али Әл-Мүттаки, «Кәнзүл-Уммал», №21484, 7/803).

2. Сәхәрне кичектерү, ифтарны ашыктыру

Сәхл Ибн Садтан (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгәнчә, Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм): «Кешеләр (вакыты җиткәч) ифтар кылырга ашыккан вакытта даими хәердә булырлар», — дигән (Бохари, «Саум», 45). Бу очракта кояш баегач та ифтар кылу тиеш һәм бу бик мөһим сөннәт. «Уйунул мәзаһиб» аңлатмаларында әйтелгәнчә, ифтарны — ашыгып, сәхәрне соңарып кылу сөннәт була. Чөнки төнлә ураза тоту бидгать гамәл. Ифтар кичектерелсә, кеше төнлә ураза тоткандай бидгать гамәл кылган була. Әбү Һурайра (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) Аллаһы Тәгаләнең:

«Иң сөекле колларым — уразаларын алдан ачучылар», - дип әмер иткәнен сөйләгән (Тирмизи, «Саум», 13, №700, 3/83).

Ибн Гомәр (радыйаллаһу ганһү) тапшырганча, Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дигән:

«Өч нәрсә рәсүлләрнең сөннәте була: сәхәрне кичектерү, ифтарны ашыктыру, намазда уң кулны сул кулның өстенә, көндек астына кую» (Табәрани, «Әвсад», №1905; «Сагыйр», №279; «Кәбир», 11/7, Хәйсәми, №4880-4882, 3/368-369; Зәбиди, «Итхаф», 3/37; «Бәдайигус Санайи», 2 том, 105 б.).

Сәхәрне кичектерүнең мөстәхәблеге көндез тотасы уразага ярдәм итүендә. Моның мөстәхәб булуы төн дәвамында шикләнмәүдә. Әгәр шик-шөбһә бар икән, дөрес караш нигезендә, бу мәкруһ була. Мәсәлән, «Бәдайи» дип аталган әсәрдә дә шулай диелгән.

Һава болытлы булган чакта, ифтарны ашыктыру мөстәхәб түгел. Якынча фараз кылу буенча кояш батмастан ифтар кылырга ярамый. Мәәзин азан әйткән булса да (Ибн Габидин, «Рәддүл Мохтар», 1 том, 420 б.).

3. Кеше таң ату хакында шикләнә торган булса, аның өчен ашамыйча тору мөстәхәб була. Әбү Йосыф (рәхмәтуллаһи галәйһи) Әбү Хәнифәнең (рәхмәтуллаһи галәйһи) сөйләгәннәрен тапшырган. Әбү Хәнифә (рәхмәтуллаһи галәйһи) болай дигән: «Таң ату-атмау турында шик-шөбһә бар икән, ашамыйча тору минем өчен яхшырак». Чөнки таңның аткан булу ихтималы бар. Алдан ашап кую уразаны бозарга мөмкин. Димәк, мондый очракларда сак булырга кирәк. Таңның ату-атмау мәсьәләсендә шөбһәләнелгән чакта ашасаң, казаның вәҗиб булуы хөкеме чыгарылмас. Чөнки уразаның бозылуында шик бар.

Кояшның батуыннан шикләнелсә, ифтар кылу дөрес булмас. Чөнки кояшның батмаган булу ихтималы бар. Бу очракта ифтар кылу уразаны бозарга мөмкин. Кояшның батуында шикләнелә торган булып, ифтар кылынса һәм моннан соң да

бу хәлгә ачыклык кертелмәсә, «Асл» исемле әсәрдә дә, Кудуринең «Мухтасарул Кәрһи» әсәрендә дә бу хакта бер нәрсә дә әйтелмәгән. «Мухтасарут Тахави» дип аталган әсәрдә Казый әйткән: «Бу очракта каза кылу тиеш» («Бәдайиус Санайи», 2 том, 106 б.).

4. Ураза тотучының тоткан уразасы кабул ителсен өчен ифтар вакытында укый торган догасы да сөннәт. Мәсәлән, Ибн Гомәр (радыйаллаһу ганһү) тапшырганча, Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) ифтар кылганда: «Сусавым басылды, тамырларым суланды, иншә Аллаһ, әҗеренә ирештем», — дия торган иде (Әбү Дауд, «Сыйам», 22, №2357, 343 б.).

Мөгаз Ибн Зүһрә (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер риваятьтә Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) ифтар кылганда: «Әй, Аллаһым! Синең өчен ураза тоттым һәм Синең ризыкларың белән авыз ачам», — дия торган булган (Әбү Дауд, «Сыйам», 22, №2358, 343 б.).

Ибн Габбас сөйләп калдырган риваятьтә, Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) ифтар вакытында болай дога кылган:

«Әй, Аллаһым! Синең өчен ураза тоттык. Ризыгың белән ифтар кылабыз. Бездән кабул ит, чөнки Син барысын да ишетәсең дә, беләсең дә» (Ибн Сүнни, Нәвави, «Әл-Әзкәр», 173 б.).

Габдуллаһ ибн Гамр ибн Гас (радыйаллаһу ганһү) авыз ачканда шушы доганы кылган:

«Әй, Аллаһым! Һәрнәрсәгә җитешле булган рәхмәтең белән минем гөнаһларымны гафу итүеңне үтенәм» (Ибн Мәҗа, Ибн Сүнни, Нәвави, «Әл-Әзкәр», 173 б.).

Әбүл Алийә (рәхмәтуллаһи галәйһи) болай дигән: «Ифтар вакытында һәркем:

«Барлык мактаулар Бөек һәм Җәзалаучы Аллаһы Тәгаләгә булсын. Барлык мактаулар барысын да күргән һәм барысын да белгән Аллаһы Тәгаләгә булсын. Барлык мактаулар барысына да кодрәте җиткән Аллаһы Тәгаләгә булсын. Барлык мактаулар үлеләрне терелтүче Аллаһы Тәгаләгә булсын», — дип дога кылса, барлык гөнаһларыннан арынып, анасының аны тудырган көндәге кебек саф калачак» (Абдулкадир-и Гәйлани, «Әл-Гунья», 1/335).

5. Үзен ифтар кылдырып сыйлаган кешеләргә дога кылу да сөннәт. Мәсәлән, Әнәс (радыйаллаһу ганһү) тапшырганча, Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) Сад Ибн Убадәдә (радыйаллаһу ганһү) икмәк белән зәйтүн мае ашаганнан соң:

«Яныбызда ураза тотучылар ифтар кылсын, ризыгызны яхшы күңелле кешеләр ашасын һәм фәрештәләр сезгә саләт әйтсен», — дип дога кылган (Әбү Дауд, Нәвави, «Әл-Әзкәр», 173 б.);

6. Авыз ачканда хөрмә кабу да сөннәт гамәл. Мәсәлән, Сәлман Ибн Әмир (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән: «Берегез ураза тоткач, хөрмә белән авызын ачсын, хөрмә тапмаса, су эчеп ифтар кылсын. Чөнки су — пакьләүче (сусауны баса һәм ашказанын юа)» (Тирмизи, «Зәкят», 26; Нәсаи, «Сыйам», 28; Ибн Мәҗа, «Сыйам», 25; Әбү Дауд, «Сыйам», 21, №2355; Әхмәд Ибн Хәнбәл, 4/17-18, 213-215).

Әнәс Ибн Мәлик (радыйаллаһу ганһү) болай дигән: «Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) намаз укыганчы өлгергән хөрмә белән авыз ача иде. Яңа өлгергән хөрмә тапмаса, кипкән хөрмә белән ифтар кыла иде. Анысы да булмаса, берничә йотым су эчә иде» (Әбү Дауд, «Сыйам», 21, №2356, 343 б.).

Имам Раббани (рәхмәтуллаһи галәйһи) язган бер хатында бу хакта болай дигән: «Хөрмәнең бәрәкәтле булуы, аның агачы кеше кебек барлык бәрәкәтләрне туплау үзенчәлеге һәм гаделият (туры һәм төз үсүе) сыйфаты белән яратылган булуында. Ул Адәм галәйһиссәләмнән калган балчыктан яратылганга күрә, Пәйгамбәребез (саләллаһу галәйһи вәссәләм) аны «Адәм углының апасы» дип атаган. Мәсәлән, Галидән (радыйаллаһу ганһү) тапшырылган бер хәдистә Рәсүлуллаһ саләллаһу галәйһи вәссәлам:

«Апагыз булган хөрмә (финик) белән сыйлагыз. Чөнки ул Адәм галәйһиссәләмнән калган балчыктан яратылган», — дип әмер иткән («Кәнзул-Уммал», 12/338, №35300).

Хөрмәне бәрәкәтле дип атау аның барлык бәрәкәтләрне туплау үзенчәлегеннән килә. Аның җимеше белән авыз ачу ураза тоткан кешенең үз кисәге белән ифтар кылуын белдерә. Бу уңайдан хөрмә ашаган кеше аның хакыйкатенә салынган чиксез камиллекне (фазыйләте һәм өстенлекләре) үзендә туплаган була. Бу мәгънә хөрмәнең теләсә кайсы вакытта ашалуында хасил булса да, ураза тотучы өчен, комачаулаучы җенси теләкләрдән һәм вакытлы ләззәтләрдән тыелып торуы сәбәпле, ифтар вакытында тагын да фазыйләтлерәк булыр һәм бу мәгънәнең авыз ачканда барлыкка килүе кешене тагын да камилләштерә.

Әбү Һурайра (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребезнең (саләллаһу галәйһи вәссәләм):

«Хөрмә (финик) мөселманның иң яхшы ифтар ризыгы», — дип әйтеп, хөрмәнең файдасы кеше хакыйкатен тулыландырганны белдергән (Әбү Дауд, «Сыйам», 16, №2345).

Һич тә ризыкның хакыйкатен тулыландырудан түгел. Бу мәгънәгә уразалы килеш ирешеп булмаганга күрә, хөрмә белән сәхәр ашарга киңәш ителгән. Хөрмәдә барлык ашала торган нәрсәләрнең файдасы бар һәм хөрмәнең бәрәкәте ифтар вакытына кадәр дәвам итә. Шушы ризык файдасы бары тик шәригать рөхсәт иткән рәвештә генә тукланганда, шәригатьнең чикләреннән кыл кадәр дә чыкмаганда гына барлыкка килә. Шулай ук бу файданың хакыйкате хөрмә ашаган кеше бары тик хакыйкатькә һәм күңел тынычлыгына ирешкән, Аллаһны зикер итүеннән йөрәге хозурланган булганда гына тормышка аша. Бу очракта ризыкның тышкы күренеше ашаучының гәүдәсенә ярдәм итәр. Ризыкның эче ашаучының тышкы кыяфәтен камилләштерер (ризыкта булган рухи көч ашаучының рухи көчен үстерүгә сәбәп була).

Югыйсә ашалган ризыкның файдасы бары тик тышкы кыяфәткә генә бәйле булыр, аны ашаган кеше рухи яктан кимчелекле булып калыр.

«Башта ашыйсы ризыгыңны җәүһәр итәргә тырыш, аннан соң җаның теләгәнне аша».

Бу сүзләр (ризыкның ашаучыны тулыландыруы турында) ифтарны ашыктыруның, сәхәрне кичектерүнең сере. Вәссәлам («Әл-Мәктүбәтүр Раббаниййә», 1/141-142).

7. Кайберәүләр ялгыш аңлаганча, рамазан уразасыннан тыш нәфел уразасы тоткан кеше янында ризык ашау мәкрүһ булмыйча, киресенчә, ураза тотучының савабын арттыруга сәбәп булган сөннәт санала. Мәсәлән, Өмме Игъмарә һәм Бүрәйдә (радыйаллаһу ганһүмә) тапшырган риваятьтә Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) Билалны (радыйаллаһу ганһү) табынга чакырган. Билал: «Мин ураза тота идем», - дигәч, Рәсүлүллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәләм) болай дип әйткән: «Ураза тотучы янында ашаганда, ризык ашалып беткәнчегә кадәр фәрештәләр уразалы кешегә саләт (дога) әйтеп торырлар. Без ризыкларыбызны ашаганда (уразалы кеше) Билалның мул ризыгы җәннәттә көтә. Әй, Билал! Беләсеңме? Уразалы кеше янында ашалган вакытта сөякләре тәсбих итәр һәм фәрештәләр аның өчен ярлыкау сорарлар» (Мүнзири, «Әт-Тәргыйб», №1627-1628, 2/145-146; Табәрани, Әвсад, Хәйсәми, №5225, 3/458).

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин.**

## Ураза

Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:

1) борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту;
2) бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту;
3) якынлык кылу.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләр мөстәхәб (мактаулы):

1) таң атканчы төнлә торып сәхәр ашау;
2) авыз ачуны соңа калдырмау;
3) изге гамәл-гыйбадәтләрне арттыру;
4) Изге Коръәнне уку һәм ятлау.

Ураза вакытында көндезен түбәндәге 10 төрле эшне кылу мәкрүһ (шелтәле) санала:

1) файдасыз һәм әдәпсез сүзләр сөйләү;
2) озак вакыт мунчада булу яки суга чумып коену;
3) ризык һәм сагыз чәйнәү;
4) берәр азыкка телне тидереп карау;
5) авыздан үбү;
6) ифтар кылмыйча ике көн рәттән ураза тоту;
7) авыруың артачагын белә торып ураза тоту.

Ураза тоткан кешегә түбәндәге 10 төрле эшне башкару дөрес санала:

1) сатып алыначак малны татып карау;
2) балага ризык чәйнәп бирү;
3) күзгә сөрмә тарту;
4) тешләрне пакьләү;
5) кан алдыру;
6) сөлек салдыру;
7) комган белән госел коену;
8) мунчага кереп аягүрә тирләп чыгу.

## ХӘЛӘЛ» КОМИТЕТЫ РАМАЗАНДА ХӘЛӘЛ ДИП ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН РИЗЫКЛАРГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫРГА ЧАКЫРА

Тиздән мөселманнар өчен изге Рамазан ае башлана. Шул уңайдан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлары Комитеты мөселманнарны «хәләл» дип тәкъдим ителгән ризыкларга бу айда аеруча игътибарлы булырга кирәклекне кисәтә.

Ел да нәкъ менә Рамазан вакытында гадәттәгедән күбрәк тапкыр хәләл товарлар белән кызыксыну арта. Сәүдәгәрләр, җитештерүчеләр шушы күренештән файда күреп калу максатыннан сатып алучыларны үз товарларының хәләл булуына төрле юллар белән ышандырырга тырыша. Мәсәлән, ярлыкларга «ит пилмәне», «мөселманча», «татар пилмәне» кебек сүзләрне өстиләр. Бу сүзләр әле ризыкның чынлап та хәләл булуын расламый.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлар Комитеты җитәкчесе Марат Низамов сүзләренә караганда, барлык мөселманнарга ризыклар сатып алганда игътибарлырак булырга кирәк. «Хәләл» стандартлар Комитеты тикшерүен узган һәм комитет реестерына кертелгән оешмалар җитештергән ризыкларның хәләл булуы шик тудырмый. Комитетта сертификация узган предприятиеләр исемлеге белән halalrt.com сайтыннан танышырга мөмкин.

«Хәләл икән, димәк аңар зыянлы өстәмәләр кушылмаган, ит ризыгы булса, ул тиешле таләпләр үтәлеп эшкәртелгән. Ләкин «хәләл» сүзенең синонимнарын кулланып ялганга баручылар бар. «Мөселманча» дип кенә язу, ул хәләл дигән сүз түгел әле. Безнең аша тикшерү үткән һәм хәләл икәнлеге расланган ризыкларга «Хәләл» стандартлар комитетының билгесе куела», - дип кисәтә Марат әфәнде.

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы «Хәләл» стандарты Комитетының матбугат үзәге.**

# Хуш киләсең, изге Рамазан!

| Май, июнь | Көн исеме | Рамазан | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам | | | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | | | Кояш чыга | | | Зәвал | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам авыз ачу | | | Ясту, тәравих | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 27 | Шм | 1 | 02.51 | 01.00 | 01.13 | 03.21 | 01.30 | 01.43 | 04.51 | 03.00 | 03.13 | 13.12 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.50 | 17.05 | 17.18 | 21.36 | 19.55 | 20.07 | 23.05 | 21.25 | 21.38 |
| 28 | Як | 2 | 02.50 | 00.59 | 01.12 | 03.20 | 01.29 | 01.42 | 04.50 | 02.59 | 03.12 | 13.12 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.51 | 17.06 | 17.19 | 21.37 | 19.56 | 20.08 | 23.06 | 21.26 | 21.40 |
| 29 | Дш | 3 | 02.49 | 00.58 | 01.10 | 03.19 | 01.28 | 01.40 | 04.49 | 02.58 | 03.10 | 13.13 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.52 | 17.07 | 17.20 | 21.39 | 19.58 | 20.10 | 23.07 | 21.28 | 21.41 |
| 30 | Сш | 4 | 02.48 | 00.56 | 01.09 | 03.18 | 01.26 | 01.39 | 04.48 | 02.56 | 03.09 | 13.13 | 11.27 | 11.40 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.53 | 17.08 | 17.21 | 21.40 | 19.59 | 20.11 | 23.09 | 21.29 | 21.43 |
| 31 | Чш | 5 | 02.46 | 00.55 | 01.08 | 03.16 | 01.25 | 01.38 | 04.46 | 02.55 | 03.08 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.52 | 17.09 | 17.22 | 21.41 | 20.01 | 20.13 | 23.10 | 21.31 | 21.44 |
| 1 | Пж | 6 | 02.45 | 00.54 | 01.07 | 03.15 | 01.24 | 01.37 | 04.45 | 02.54 | 03.07 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.53 | 17.10 | 17.23 | 21.41 | 20.02 | 20.15 | 23.11 | 21.32 | 21.45 |
| 2 | Жм | 7 | 02.44 | 00.53 | 01.06 | 03.14 | 01.23 | 01.36 | 04.44 | 02.53 | 03.06 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.54 | 17.11 | 17.24 | 21.43 | 20.03 | 20.17 | 23.13 | 21.33 | 21.47 |
| 3 | Шм | 8 | 02.44 | 00.52 | 01.05 | 03.14 | 01.22 | 01.35 | 04.44 | 02.52 | 03.05 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.55 | 17.12 | 17.25 | 21.44 | 20.05 | 20.18 | 23.14 | 21.35 | 21.48 |
| 4 | Як | 9 | 02.43 | 00.51 | 01.04 | 03.13 | 01.21 | 01.34 | 04.43 | 02.51 | 03.04 | 13.13 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.55 | 17.12 | 17.25 | 21.45 | 20.06 | 20.19 | 23.15 | 21.36 | 21.49 |
| 5 | Дш | 10 | 02.42 | 00.50 | 00.03 | 03.12 | 01.20 | 01.33 | 04.42 | 02.50 | 03.03 | 13.14 | 11.28 | 11.41 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.56 | 17.13 | 17.26 | 21.46 | 20.07 | 20.21 | 23.16 | 21.37 | 21.51 |
| 6 | Сш | 11 | 02.41 | 00.49 | 01.02 | 03.11 | 01.19 | 01.32 | 04.41 | 02.49 | 03.02 | 13.14 | 11.28 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.57 | 17.14 | 17.27 | 21.47 | 20.08 | 20.22 | 23.17 | 21.38 | 21.52 |
| 7 | Чш | 12 | 02.40 | 00.49 | 01.01 | 03.10 | 01.19 | 01.31 | 04.40 | 02.49 | 03.01 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.57 | 17.14 | 17.27 | 21.48 | 20.09 | 20.23 | 23.18 | 21.39 | 21.53 |
| 8 | Пж | 13 | 02.40 | 00.48 | 01.01 | 03.10 | 01.18 | 01.31 | 04.40 | 02.48 | 03.01 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.58 | 17.15 | 17.28 | 21.49 | 20.10 | 20.24 | 23.19 | 21.40 | 21.54 |
| 9 | Жм | 14 | 02.39 | 00.47 | 01.00 | 03.09 | 01.17 | 01.30 | 04.39 | 02.47 | 03.00 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.58 | 17.15 | 17.29 | 21.50 | 20.11 | 20.25 | 23.20 | 21.41 | 21.55 |
| 10 | Шм | 15 | 02.39 | 00.47 | 01.00 | 03.09 | 01.17 | 01.30 | 04.39 | 02.47 | 03.00 | 13.15 | 11.29 | 11.42 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.59 | 17.16 | 17.29 | 21.51 | 20.12 | 20.26 | 23.21 | 21.42 | 21.56 |
| 11 | Як | 16 | 02.38 | 00.46 | 00.59 | 03.08 | 01.16 | 01.29 | 04.38 | 02.46 | 02.59 | 13.15 | 11.29 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.59 | 17.16 | 17.30 | 21.52 | 20.13 | 20.27 | 23.22 | 21.43 | 21.57 |
| 12 | Дш | 17 | 02.38 | 00.46 | 00.59 | 03.08 | 01.16 | 01.29 | 04.38 | 02.46 | 02.59 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.00 | 17.17 | 17.30 | 21.53 | 20.14 | 20.27 | 23.23 | 21.44 | 21.57 |
| 13 | Сш | 18 | 02.37 | 00.45 | 00.58 | 03.07 | 01.15 | 01.28 | 04.37 | 02.45 | 02.58 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.00 | 17.17 | 17.31 | 21.53 | 20.15 | 20.28 | 23.23 | 21.45 | 21.58 |
| 14 | Чш | 19 | 02.37 | 00.45 | 00.58 | 03.07 | 01.15 | 01.28 | 04.37 | 02.45 | 02.58 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.01 | 17.18 | 17.31 | 21.54 | 20.16 | 20.29 | 23.24 | 21.45 | 21.59 |
| 15 | Пж | 20 | 02.37 | 00.45 | 00.57 | 03.07 | 01.15 | 01.28 | 04.37 | 02.45 | 02.58 | 13.15 | 11.30 | 11.43 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.18 | 17.32 | 21.55 | 20.17 | 20.29 | 23.25 | 21.46 | 21.59 |
| 16 | Жм | 21 | 02.37 | 00.45 | 00.57 | 03.07 | 01.15 | 01.27 | 04.37 | 02.45 | 02.57 | 13.15 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.18 | 17.32 | 21.55 | 20.17 | 20.30 | 23.25 | 21.47 | 22.00 |
| 17 | Шм | 22 | 02.37 | 00.45 | 00.57 | 03.07 | 01.15 | 01.27 | 04.37 | 02.45 | 02.57 | 13.15 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.02 | 17.19 | 17.32 | 21.56 | 20.17 | 20.30 | 23.26 | 21.47 | 22.00 |
| 18 | Як | 23 | 02.37 | 00.45 | 00.57 | 03.07 | 01.15 | 01.27 | 04.37 | 02.45 | 02.57 | 13.15 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.19 | 17.32 | 21.56 | 20.18 | 20.31 | 23.26 | 21.48 | 22.01 |
| 19 | Дш | 24 | 02.37 | 00.45 | 00.57 | 03.07 | 01.15 | 01.27 | 04.37 | 02.45 | 02.57 | 13.15 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.19 | 17.33 | 21.56 | 20.18 | 20.31 | 23.26 | 21.48 | 22.01 |
| 20 | Сш | 25 | 02.37 | 00.45 | 00.58 | 03.07 | 01.15 | 01.27 | 04.37 | 02.45 | 02.57 | 13.15 | 11.31 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.33 | 21.57 | 20.18 | 20.32 | 23.27 | 21.48 | 22.02 |
| 21 | Чш | 26 | 02.37 | 00.45 | 00.58 | 03.07 | 01.15 | 01.28 | 04.37 | 02.45 | 02.58 | 13.15 | 11.32 | 11.44 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.33 | 21.57 | 20.18 | 20.32 | 23.27 | 21.48 | 22.02 |
| 22 | Пж | 27 | 02.37 | 00.45 | 00.58 | 03.07 | 01.15 | 01.28 | 04.37 | 02.45 | 02.58 | 13.15 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.34 | 21.57 | 20.19 | 20.32 | 23.27 | 21.48 | 22.02 |
| 23 | Жм | 28 | 02.37 | 00.45 | 00.58 | 03.08 | 01.15 | 01.28 | 04.37 | 02.45 | 02.58 | 13.15 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.03 | 17.20 | 17.34 | 21.57 | 20.19 | 20.32 | 23.27 | 21.49 | 22.02 |
| 24 | Шм | 29 | 02.38 | 00.46 | 00.59 | 03.08 | 01.15 | 01.29 | 04.38 | 02.46 | 02.58 | 13.16 | 11.32 | 11.45 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 19.04 | 17.21 | 17.34 | 21.57 | 20.19 | 20.32 | 23.27 | 21.49 | 22.02 |

## Ураза тотарга ният кылганда укыла торган дога

**Нәвәйтү ән әсумә шәһри Рамадаанә минәлфәҗри иләәл-мәгъриби хаалисал – лилләәһи тәгъәәләә.**

**Тәрҗемәсе:** Аллаһы Тәгалә өчен чын күңелдән ният кылдым ошбу көннең фарыз уразасын тотарга, таң атканнан алып кояш баеганчыга тикле.

**Искәрмә:** Рамазан ае башлану яңа туган ай күренүгә бәйле. Намаз һәм сәхәр вакыты Татарстан мөселманнары Дини нәзарәте тарафыннан билгеләнде.

## Авыз ачкач ошбу дога укыла:

**Бисмилләһир-рахмәәәнир-рахим!**

**Аллаһүммә ләкә сүмтү, үә бикә әәмәнтү үә гъәләйкә тәүәккәлтү үә гъәләә ризкыйкә әфтартү, үә лисауми гадин шәһри Рамадаанә нәвәйтү, фәгъфир лий йәә Гаффәәру мәә каддәмтү үәмәә әхъхартү. Бирахмәтикә йәәә әръхәмәр-раахимиин. Әмин.**

**Тәрҗемәсе:** Әй, Аллаһым! Ошбу уразамны Синең өчен генә тоттым һәм Сиңа гына иман китердем, вә Сиңа тәвәккәл кылдым; вә Синең ризыгың белән авызымны ачамын. Әй, гөнаһларны ярлыкаучы Раббым! Минем моңа кадәр кылган гөнаһларымны да, соңгыларын да ярлыкасаң иде. Әмин.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Динияя нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан саклануырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 4 май 16 сәг. фактта 4 май 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**